| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

29.12.2014 Казан ш. 3060-р

**Татарстан Республикасы Буа, Апас (өлешчә), Тәтеш (өлешчә) муниципаль районнары территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында" 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәренә хокукларны раслаучы документлар нигезендә, «Земля» Республика кадастр үзәге» ААҖ (алга таба - «Земля» РКЦ ААҖ) башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. Газ бүлү челтәренең (газүткәргечләрнең) саклык зоналары чикләрен расларга:

1.1 Буа муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 645,895 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 2,59256 кв.км (2 592 560 кв.м) территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газүткәргечне «Земля» РКЦ» ҖЧҖ тарафыннан 2014 елның 21 ноябреннән 1 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ 2014 елның 19 декабрендә раслаган җир өсте һәм җир асты объектларының саклык зонасы картасына (планына) нигезләнеп.

1.2. Апас муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 2,730 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 10 935 кв.м территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газүткәргечне «Земля» РКЦ» ҖЧҖ тарафыннан 2014 елның 21 ноябреннән 1 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ 2014 елның 19 декабрендә раслаган җир өсте һәм җир асты объектларының саклык зонасы картасына (планына) нигезләнеп.

1.3. Тәтеш муниципаль районы территориясендә (өлешчә) урнаштырылган, 3,818 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 15 298 кв.м территорияне тәшкил иткән, инвентарь номеры әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газүткәргечне «Земля» РКЦ» ҖЧҖ тарафыннан 2014 елның 21 ноябреннән 1 декабренә кадәр әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ 2014 елның 19 декабрендә раслаган җир өсте һәм җир асты объектларының саклык зонасы картасына (планына) нигезләнеп.

2. Газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән, әлеге карарның 2 нче кушымтасындагы җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында" 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлү челтәренең саклау зоналары турында мәгълүматны дәүләт күчемсез милек кадастрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газ бүлгеч челтәрнең саклык зонасына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә чикләүләр кертелү турында мәгълүматны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны Татарстан Республикасы буенча "Росреестр федераль кадастр палатасы" филиалына юлларга, шулай ук, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Г.Э. Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**